## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге составына керүче Иске Куак торак пунктында

13 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлеге Иске Куак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләргә:

2. Алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

   - җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру, су чыгаруны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру – школьная һәм Садовая урамнарында суүткәргечне ремонтлау һәм алмаштыру.
   - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге-Ягодная, Набережная урамнарын төзекләндерү һәм вак таш салу.

«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н.Сушкова